| ГЛАВА БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>422658, с. Большой Машляк<br>ул. Центральная<br>дом 20 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР МӘШЛӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ<br>422658, Зур Мәшләк<br>Центральная урамы<br>20 нче йорт |
|---|---|

Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru

**Постановление** **Карар**

2022 елның 09 ноябре Зур Мәшләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Югары Мәшләк авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Зур Мәшләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Югары Мәшләк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 24 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Югары Мәшләк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

-Зур Мәшләк торак пункты территориясендә энергия саклаучы лампаларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- Торак пунктны су белән тәэмин итү;

-Торак пункт юлларын ремонтлау, кышкы карап тору һәм хезмәтләр өчен түләү

«КАРШЫ» “ЯКЛЫЙМ”

Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин